**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 30 ноябре                                                  № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2025 елның 30 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк торак пункты узган территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан тыш, 2026 елда 700 (Җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Үрнәк-Күмәк авылында урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үрнәк-Күмәк авылындагы Урман, Мәктәп, Бакча, Дуслык, Төзелеш урамнары буенча юлларны кардан чистарту);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Үрнәк-Күмәк авылындагы балалар мәйданчыгын төзекләндерү - мәйданнарны планлаштыру, туфрак эшкәртү, нигезне комнан түшәү һәм тигезләү катламнарын урнаштыру);

4) су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Үрнәк-Күмәк авылында су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларының өзеклекләрен бетерү);

5) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Үрнәк-Күмәк авылының Урман урамы буенча урнашкан чишмәне төзекләндерү һәм чистарту).

«РИЗА»                                        «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 128 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 70 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 70 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк -Күмәк торак пункты узган территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 700 (Җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Үрнәк-Күмәк авылында урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үрнәк-Күмәк авылындагы Урман, Мәктәп, Бакча, Дуслык, Төзелеш урамнары буенча юлларны кардан чистарту);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Үрнәк-Күмәк авылындагы балалар мәйданчыгын төзекләндерү - мәйданнарны планлаштыру, туфрак эшкәртү, нигезне комнан түшәү һәм тигезләү катламнарын урнаштыру);

4) су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Үрнәк-Күмәк авылында су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларының өзеклекләрен бетерү);

5) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Үрнәк-Күмәк авылының Урман урамы буенча урнашкан чишмәне төзекләндерү һәм чистарту) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Үрнәк-күмәк авылы үзидарә администрациясе бинасында Мәктәп урамы 3а йорт, Глазов авылы, Заречная ур., 13 йорт, Петропавловк авылы, Горький ур., 19а йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Глазово авыл җирлеге башлыгы Н.К.Карабаева